ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАГРЯЖСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАГРАЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22.08.2025** **№ 21**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Баграж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмеш лампаларын туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү хакында» 2023 елның 27 мартындагы 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында нигезләмәне раслау хакында» 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Баграж авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Баграж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 27 мартындагы 7 номерлы карарының 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы «Баграж авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә әйләнә-тирә мохит

торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат урнаштыру юлы белән эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыннарының урнашуы турында кулланучыларга мәгълүмат бирергә.».

2. Әлеге карарны җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **П.Н. Минеев**